

Ташны-ташка куеп, кvз алдында дивар-стена барлыкка килә, ул бинанын бер элементы. Шулай халыкнын яшәv урыны, мәктәп-бакчалар, заводлар барлыкка килә. Тозvче - бик тә жаваплы профессия.
Тозvче һонәре турында торле фикерләр яши: кайсылары анын бик авыр хезмәт булуын, янгыр-буранда, ачы жилләрдә ачык һавада эшләргә, авыр йокләр кvтәрергә туры килгәнен расласа, кемнәрдер хезмәтенен жинел һәм кvнелле булуын тасвирлый. Шулай да нинди сон ул тозvче һонәре? Бишенче разряд белән хезмәт иткән,  ташчы һонәренә тормышын багышлаган Наиль Фатих улы Хамидуллов кvп йорт салган, димәк, анардан да яхшырак жавап бирvче табып та булмас.      Наиль Фатих улы Хамидуллов Ләмберәдә 1961нче елны доньяга аваз сала. Ләмберәдә ук топ мәктәпне тәмамлый. Кем булырга, нинди профессия vзләштерергә дип озак уйламыйча, Ләмберәдә илебез авыл хужалыгына кадрлар әзерли торган ГПТУ-12  (элек шулай диелгән) укырга керә. Ул анда тимербетон конструкцияләре буенча ташчы-монтажник белгечлеге буенча белем ала. Сонында аны Саранскнын  ПМК-280нен ташчылар бригадасына, элек шулай эшкә юллый иделәр, жибәрелә. Шул арада Наиль Фатих улына хәрби хезмәткә чакырылу вакыты да житә. Ул вакыт нинди инде ир-атка Ватанына хезмәт итми калу, андый фикерләр башка да килмәгән; хәрби хезмәткә алына ул. Военкомат аны ДОСААФ ка юллый. Кvпторле белгечләр әзерләv белән бергә, анда машина йортvчеләр әзерли булганнар. Наиль Хамидулловны да, шофер профессиясен vзләштерергә, укуларга жибәрәләр. Анда укып чыккач, 1980 елда, армия сафында хезмәтен Ярославль тимер юлы частендә башлап жибәрә. 10чы аерым понтон ротасында 1982 елга кадәр хезмәт итә. Ул заманаларда икешәр ел хәрби хезмәт иткәннәр, бvген - бер ел.
Исән-сау туган Ләмберәсенә кайта Наиль Фатих улы Хамидуллов. Мордовиядә унышлы эшләрен алып баручы «Мордовмелиорация» дигән тозv-мелиорация оешмасына, демобилизациядән сон, ташчы булып эшкә урнаша. Халык бvген дә Ләмберәдәге микрорайонны «Мелиорация» дип йортә. Биредәге йортларны тозvгә керткән олеше Наиль Фатиховичнын зур. Шул йортларда якташлары бvген дә рәхәтләнеп яши.
Вакыт vзгәрә һәм тормышка vз коррективларын кертә. Шулай язма героебыз, ташчы профессиясенә тугры калып, ОАО «Мордовсельстрой» трестына хезмәткә урнаша. Аннары ун ел чамасы ООО «Саранскстройзаказчик»та тырышып хезмәт итә. Кыскасы, республикабыз тозелешендә черек гасыр, 25 ел армый-талмый хезмәт куя ул. Авыр тугзанынчы елларда, Мордовиябез халкы Мәскәv һәм башка чит жирләргә эшкә киткән вакытларда да, туган республикасыннан ерак китми Наиль Фатих улы Хамидуллов. Ул:

«Заманалар vзгәрер, халык янадан эшле булыр», - дип ышана. Шулай булды да. Кvп жирләрдә - регионыбыз шәһәрләрендә һәм авылларда кешеләргә шатлык китергән тозvчебез, сонгы елларда футбол буенча Ботендонья чемпионатына әзерлек барган кызу чакта, «Тавла» дигән яшәv комплексын този. Саранск башкалабызнын «Химмаш»ы башланган урында, Емельян Пугачев һәйкәле артындагы матур һәм яшәv очен унайлы шартлар тудырылган кvпкатлы йортны тозегәндә, оста ташчысыз берничек тә булмый. Наиль Хамидуллов салган йортта бvген халык рәхәтләнеп яши, чонки ташчыбыз бар кvнелен биреп, тырыш салган бу бинаны.
Наиль Фатих улы бvген лаеклы ялда, льготалы пенсиядә. Халыкка яхшы булсын дип тырышып хезмәт итә ул, ә бvләкләр турында уйлаганы да булмый; житәкчеләр тарафыннан чын эшчеләр еш онытылып та кала. Хезмәттәшләре белән һәрвакыт уртак тел таба белә, ул тозегән йортларда кешеләргә яшәргә яхшы булсын дип тырыша. Авыр хезмәте турында:
- Эшемне бик яратып башкардым. Әле бvген дә кvз алдымда: бинанын нигезен салып йорисен, кемнәр монда яшәр икән дип уйлый-уйлый кирпеч артыннан кирпеч саласын... ә кvпмедер вакыттан мәһабәт бина калкып чыга. Тиздән әлеге йортларда яши дә башлыйлар. Кичләрен тәрәзәләре якты утларга кvмелгән йортларны кvреп кvнел соенә... Һонәремне кем начар яктан тасвирлый алыр икән?! Бәлки яшьтән эшләп vскәнгәдер, ул мина бер дә авыр тоелмады…
Шәхси тормышында да анын тәртип; чын ир. Туган Ләмберәсенен Крестьяннар дигән урамында vз куллап йорт сала. 1989нчы елны Лариса Монир кызы Бояровага өйләнә. Алар ике ир бала тәрбияләп vстерәләр. Эльнарлары -  Н.П. Огарев исемендәге МГУны тәмамлап ООО «Ростелеком»да программист булып эшли, Ильгизләре - шул ук университетнын механизация факультетын тәмамлап, ООО «Нива»да инженер-механик булып тырышып хезмәт итә. Бvген Наиль Фатих улы Хамидуллов 56ны тутырса да, ул кvзгә бик яшь кvренә. Шуна карамастан, бабай булып та олгергән - Дариночка оныклары vсеп килә.
Бу ташчы турында шундый нәтижә ясарга була: эчке доньяннын торышы һонәрнен нинди булуыннан тормый, ә синен аны яратуына, vз итvенә, ләззәт һәм канәгатьләнv алуына бәйле. Кондәлек эшен жинел кабул итvе, һәр коненнән ниндидер шатлыклы вакыйгалар табуы жиңеләйтә дә инде Наиль Фатих улы Хамидулловнын авыр да, мактаулы да хезмәтен.

**Н.Хәлил**